# ZALYAY LATIF'S MULTIFACETED RESEARCH ACTIVITY

**Mirfatykh Zakievich Zakiev,**
Academy of Sciences, the Republic of Tatarstan,
20 Bauman St., Kazan, 420111, Russia,
m.z.zakiev@mail.ru



**ZALYAY (Zalyaletdinov) LATYF ZALYALETDINOV** (1894-1966) is a linguist, PhD (1954), Professor (1958), worked at Kazan Teacher Training Institute (since 1935) and at the Institute of Language and Literature of Kazan branch of the USSR Academy of Sciences (since 1941), Head of the Linguistics Sector of Kazan branch of the USSR Academy of Sciences in 1951-53, 1956-61.

Studies and publications on Dialectology, Historical Phonetics, Grammar, Orthoepy, and Stylistics of the Tatar language.

**ЛАТЫЙФ ҖӘЛӘЛЕТДИН улы ҖӘЛӘЛЕТДИНОВ** (1894-1966) − тел-әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (1954), профессор (1958). 1935 елдан Казан дәүләт педагогия институтында, 1941 елдан Татар тел, әдәбият һәм тарих фәннитикшеренү институтында, 1951-53, 1956-61 елларда тел белеме секторы мөдире.

Хезмәтләре татар теленең диалектологиясе, тарихи фонетика һәм грамматикасы, орфоэпия һәм стилистикасына карый.

**ЗАЛЯЙ (Залялетдинов) ЛАТЫФ ЗАЛЯЛЕТДИНОВИЧ** (1894-1966) − языковед, доктор филологических наук (1954), профессор (1958). С 1935 г. в Казанском государственном педагогическом институте, с 1941 в Татарском научно-исследовательском институте языка, литературы и истории, в 1951-53, 1956-61 гг. заведующий сектором языкознания Института языка, литературы и истории КФАН АН СССР.

Труды по диалектологии татарского языка, исторической фонетике и грамматике, орфоэпии и стилистике.

Latyf Zalyaletdinov (Latyf Zalyay) was born on the 17$^{th}$ November, 1894 into a poor peasant family living in the village of Iske Kyzyl Su of Keche Kandal district in Ulyanovsk region. To help the family Latyf did odd jobs since he was 9. At that time, he learned Russian sociolizing with Russian children. In winter, he went to a village school, and in 1906, he moved to a bigger settlement – Malaska – where he continued his studies and made his own living. Latyf was studying in the medrese when his parents died. But this sorrowful event did not discourage him. He completed a two-year course in medrese in one year and in 1912 he began his teaching career in Iske Juray village (at present it is in Samara region). Teachers were very badly paid in those times and he could survive only thanks to his pupils' charity. Being unable to bear this misery, in 1914, accompanied by one of his friends, Latyf moved to Tashkent in search of happiness. There he worked as a porter and a cook. In 1915 Zalyay joined the army, was contused World War I, was taken to hospital in Moscow, and after the recovery he returned to the front. During the February Revolution of 1917 he was in Romania, later, in October 1917 when Bolshevik Revolution burst out in the country Latif, discharged from the army, was living in his village.

After the Bolshevik Revolution, Latyf eagerly resumes his favourite job. After 3 years in his native village, in 1921, he was sent to Samara as the head of an orphanage and a teacher of the Tatar language and literature. At that time, he got interested in literature and wrote poems and plays. He worked in the Education Department in Bozaulyk province in 1925-27, later, in 1928-29, Latyf worked as an inspector in Samara province. In 1929-31, as a teacher of Tatar, he first worked in Kuznetsk and later on in a Communist Party school of Malakast and started a postgraduate course at Samara Agricultural College. But the Tatar graduate center was closed in 1933, and Latyf Zalyay had to move to Kazan to do a postgraduate course at the Teacher Training Institute. He completed the course in 1935, and began to teach Tatar dialectology and the history of Tatar literature at the Institute. Latyf Zalyay worked as the head of the Tatar Language Department of the Institute of Language, Literature and History from (since) 1939 to 1962. At the same time, he did his best to open the Tatar Language and Literature Department where he taught Dialectology and the History of language.

Latyf Zalyay's academic career began in 1920. His first work on methods of teaching children was published in 1929. Later on he published a lot of articles and study guides on teaching the Tatar language. He was actively involved in compilation of Tatar literature text-books and reading-books.

After coming back to Kazan, Latyf conducted research in the area of literary criticism. In 1934, he wrote a review of the book "Captain" by M.Amir. His scientific-critical works "A Blue Meadow", "The Language of Unfledged Writers", "Sivash", "Sh.Kamal's Role in Improving the Tatar Figurative Language" were published that time. He studied the language of G.Tukay's poetry and wrote a number of works on the subject matter. During the Great Patriotic War (World War I), Latyf Zalyay focused on literary criticism. He published articles in newspapers and magazines on the current literary issues. His thoughts about the cultural heritage of Tatar classical writers – G.Tukay, Sh.Kamal, F.Amirkhan, S.Khakim, G.Bashirov and others – have not lost their scientific and public significance [2:65; 3:19]. In spite of the fact that the scholar worked in the area of linguistics, he was also interested in the history of Tatar literature and regularly published his works in mass media. Since 1939 Latyf was a member of the USSR Union of Writers.

Latyf Zalyay conducted research in different areas of linguistics. He was a scholar who made Tatar Dialectology an independent study. As a dialectologist he organized 19 field studies with the aim to explore the ethnic vernacular, thus making a substantial contribution to the history of the Tatars studies. By analyzing the vernacular we learn the history of the language which is inseparable from the history of the Tatars. The history of language is closely connected with historical grammar. Therefore, as a dialectologist, Latyf Zalyay was engaged both in the research into the history of the literary language and the historical grammar. He presented his PhD thesis on "Some information about the history of the Tatar language" in 1938 and devised a course on the history of the Tatar literary language and historical grammar for students of the Tatar language and literature at Kazan State University and Kazan State Pedagogical Institute. Latyf Zalyay also published a number of articles in this area in different academic peer reviewed editions.

The History of language and Historical Grammar awoke the scientist's interest for Tatar dialectology. He wrote the article "Dialects in the Tatar Language" in 1938. After that he kept returning to this topic and published the first big treatise "Tatar Dialectology" in 1947. This publication made Tatar dialectology the cutting edge of Turkic dialectology. Later, the scholar extended his research on this topic. Zalyay was the first to prove the necessity and importance of compiling a dictionary of Tatar dialects. L.Zalyay did a lot to devise a list of questions for studying Tatar dialects. He continued systematical research on Tatar dialectology and defended his doctoral thesis "The Middle Tatar Dialect" in 1955. It was the culmination of his scientific research.

At that time, Latyf Zalyay was busy studying Tatar dialectology, but he did not give up his research on historical grammar. The result of his long research was one of his greatest works, the book "The Outline of Tatar Historical Morphology," completed in 1960s. Although submitted for publication to Kazan University Publishing House, it was published by the Language, Literature and Art Institute only in 2000.

Latyf Zalyay wrote important works on the relevant issues of Tatar literary language and did his best to develop Tatar literary speech culture. His book "Basic Principles of Tatar Orthoepy" published in 1953 and was the first extensive research covering the main pronunciation rules and patterns of accurate speaking.

Latyf Zalyay as a polymathic, academically trained scientist identified the guidelines of Tatar

linguistics future development. L.Zalyay wrote about the necessity of compiling a Tatar language definition dictionary, a dialect atlas and a full dialect dictionary of the stylistic analysis of Tatar, and other timely issues in his article “The Tatar Linguistics Objectives” published in the newspaper “Socialist Tatarstan” in 1956, and today, L.Zalyay’s students and colleagues successfully implement his ideas[1:6].

To conclude, Latyf Zalyaletdinov’s (Latyf Zalyay) works are the basis for the development of such content areas of linguistics as dialectology, history of literary language, historical grammar, linguohistory and speech culture.

**References**


1. *Zäkiev M.Z.* Latyyf Žäläy häm millät yazmyshy mäs'äläläre // Aktual'nye voprosy tatarskogo yazykoznaniya. Vyp. 4. Kazan', 2005. 3-18 b.
2. Zalyaletdinov Latyf Zalyaletdinovich // Kazanskaya lingvisticheskaya shkola: Kniga pervaya: Kazanskaya tyurkskaya lingvisticheskaya shkola. Kazan': Tatar. kn. izd-vo, 2008. S. 64-68.
3. *Bayazitova F.S.* Tugan tel häm Latyyf Žäläyneŋ oly mirasy // Aktual'nye voprosy tatarskogo yazykoznaniya. Vyp. 4. Kazan', 2005. 18-24 b.


# ТАНЫЛГАН ГАЛИМ ЛАТЫЙФ ҖӘЛӘЙНЕҢ КИҢКЫРЛЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ


**Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев,**
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе,
Россия, 420111, Казан ш., Бауман ур., 20,
m.z.zakiev@mail.ru


Латыйф Җәләлетдин улы Җәләлетдинов (Латыйф Җәләй) 1894 елның 17 ноябрендә Ульяновск өлкәсе Кече Кандал районы Иске Кызыл Су (русча: Тат. Урайкино) авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Ата-анага ярдәм кирәк булганлыктан, Латыйф тугыз яшьтән үк төрле җирләрдә ялланып эшли. Шул вакытта, рус балалары белән аралашып, русча өйрәнә. Кыш көннәрендә авыл мәктәбендә укый, 1906 елда Мәләкәскә китә һәм, үз тамагын үзе туйдырып, гыйлемен тирәнәйтә. Мәдрәсәдә укыган елларда яшь Латыйф әти-әнисез кала. Ләкин бу кайгылы хәл аның укуга булган омтылышын юкка чыгармый. Ул мәдрәсәнең соңгы ике елы уку программасын бер елда тәмамлый. 1912 елда хәзер Самара өлкәсенә керә торган Иске Җүрәй авылында укытучылык эшенә керешә. Аерым билгеләнгән хезмәт хакы булмаганлыктан, укытучылар балалардан кергән сәдакага гына яши торган булганнар. Латыйфны бу мохтаҗлык кимсетә, һәм ул 1914 елда үзенең бер иптәше белән Ташкентка бәхет эзләп китә; анда йөк ташучы, ипи пешерүче булып эшли. Җәләй 1915 елда солдатка алына, империалистик сугышта контузияләнә, Мәскәүдә госпитальдә ята, яңадан фронтка китә. Февраль инкыйлабын – Румыниядә, Октябрь борылышын үз авылларында, солдат шинелен салырга өлгермәгән килеш каршылый.

Октябрь инкыйлабыннан соң Латыйф ага, зур дәрт белән, үзенең яраткан эшенә кайта. Туган авылында өч ел укыткач, 1921 елда аны Самарага балалар йорты мөдире һәм педтехникумга татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп күчерәләр. Шул елларда ул әдәбият белән ныклап кызыксына башлый, үзе дә шигырьләр, пьесалар яза. 1925-27 елларда Бозаулык өязе мәгариф бүлегендә, 1928-29 елларда Самара облоносында инспектор булып эшли. 1929-31 елларда башта Кузнецк шәһәрендә, аннан соң Мәләкәстә партия мәктәбендә татар теле укыта, Самарадагы авыл хуҗалыгы техникумы аспирантурасына керә. 1933 елны, анда татар теле буенча аспирантура ябылгач, Латыйф Җәләй, Казанга килеп, пединститут аспирантурасында укуын дәвам итә. 1935 елда аны тәмамлап, әлеге югары уку йортында татар диалектологиясен һәм татар әдәби теле тарихын укыта башлый. 1939 елдан алып 1962 елга кадәр Латыйф Җәләй Тел, әдәбият һәм тарих институтында татар теле секторы мөдире булып эшли. Бер үк вакытта университетта татар теле һәм әдәбияты бүлеген оештыруда актив катнаша, шунда диалектология һәм тел тарихы курсларын укыта.

Латыйф Җәләйнең фәнни эшчәнлеге 1920 елларда башланып китә. 1929 елда аның беренче хезмәте аерым китап булып басылып

чыга. Бу – балалар тәрбияләүне оештыру методикасы турында була. Шуннан соң Л.Җәләйнең татар телен укытуга багышланган мәкаләләре һәм уку-укыту әсбаплары берсе артыннан берсе дөнья күрә. Ул татар әдәбиятыннан дәреслек-хрестоматияләр төзүдә дә актив катнаша.

Казанга килгәч, Латыйф ага әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә актив эшли. 1934 елда М.Әмирнең «Командир» исемле әсәренә рецензия яза. Бу елларда аның «Зәңгәр алан», «Башлап язучылар теле», «Сиваш», «Татар художество телен баетуда Ш.Камалның роле» гыйльми-тәнкыйть мәкаләләре басылып чыга. Г.Тукай поэзиясенең тел үзенчәлекләрен өйрәнеп, шушы темага берничә язмасын багышлый. Бөек Ватан сугышы елларында Латыйф Җәләйнең әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге тагын да активлаша. Ул шушы чор әдәби хәрәкәтендә күзәтелгән тема һәм проблема яңалыкларын яктырткан мәкаләләрен газета-журнал битләрендә бастыра. Аның татар классиклары Г.Тукай, Ш.Камал, Ф.Әмирхан, С.Хәким, Г.Бәширов һәм башка язучыларның рухи мирасы һәм аларның теле турында бүген дә гыйльми һәм гамәли әһәмиятен югалтмаган кыйммәтле фикерләре бар [2:65; 3:19]. Тел белеме өлкәсендә хезмәт итсә дә, галим татар әдәбияты тарихы белән якыннан кызыксына һәм аның хезмәтләре вакытлы матбугат битләрендә даими басылып килә. Латыйф ага − 1939 елдан бирле СССР Язучылар союзы әгъзасы.

Латыйф Җәләй − тел белеменең төрле өлкәләрендә хезмәт куя. Ул − татар диалектологиясен мөстәкыйль фән дәрәҗәсенә күтәргән галим. Диалектолог буларак, ул халыкның җанлы сөйләшен өйрәнү максаты белән 19 экспедиция оештыра. Җирле сөйләшләрне тикшерү аша татар халкы тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә. Җанлы сөйләшләрне тикшерү халык тарихыннан аерылгысыз булган тел тарихын өйрәнү өчен кирәк. Тел тарихы тарихи грамматика белән аерылгысыз бәйләнгән. Менә шуңа күрә Латыйф Җәләй, диалектолог буларак, әдәби тел тарихы һәм тарихи грамматика буенча бу елларда нәтиҗәле гыйльми эш алып бара. 1938 елда «Татар теле тарихына карата кайбер материаллар» дигән хезмәтен кандидатлык диссертациясе итеп яклый. Аның тарафыннан Казан дәүләт университеты һәм Казан дәүләт педагогия институтындагы татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары өчен әдәби тел тарихы һәм тарихи грамматика курсы һәм аның программасы төзелә. Болардан тыш Латыйф Җәләйнең шул өлкәгә караган күп кенә мәкаләләре төрле гыйльми һәм тематик җыентыкларда басыла.

Тел тарихы һәм тарихи грамматика тармаклары галимдә татар диалектологиясенә кызыксыну уята.1938 елда Латыйф ага «Татар телендә диалектлар» дигән мәкалә яза. Шуннан соң ул диалектология өлкәсендә системалы эш алып бара һәм 1947 елда аның «Татар диалектологиясе» дигән беренче зур хезмәте басыла. Югары уку йортлары өчен чыгарылган бу кулланма татар диалектологиясе фәнен, башка төрки халыклар диалектологиясе белән чагыштырганда, алдынгы урынга чыгара. Алга таба галим бу өлкәдә фәнни тикшеренү эшләрен киңәйтә. Латыйф ага, беренчеләрдән булып, татар диалектлары сүзлеген төзү мәсьәләсен көн тәртибенә куеп, аның кирәклеген исбатлый. Татар теле диалектларын өйрәнү буенча сораулыклар төзүдә Л.Җәләйнең роле аеруча зур була. Ул татар диалектологиясе юнәлешендә системалы фәнни эзләнүләр алып барып, 1955 елда «Татар теленең урта диалекты» дигән темага докторлык диссертациясе яклый.

Латыйф Җәләй бу елларда татар диалектолгиясен өйрәнү белән ныклап шөгыльләнсә дә, тарихи грамматика буенча да эзләнүләрен туктатмый. Күп елларга сузылган тикшеренүләр нәтиҗәсе буларак, аның иң зур хезмәтләреннән берсе − «Татар теленең тарихи морфологиясе буенча очерклар» китабы 1960 елларда әзерләнә. Ул Казан университеты нәшриятына тапшырылса да, басылмый кала. Бары 2000 елда гына Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында дөнья күрә.

Латыйф ага Җәләй үз чоры татар әдәби теле проблемалары буенча да әһәмиятле хезмәтләр яза, татар әдәби сөйләм культурасын үстерү юлында күп тырышлык күрсәтә. Аның 1953 елда чыккан «Татар теленең орфоэпик нигезләре» дигән китабы татарча дөрес әйтү, дөрес сөйләүнең төп кагыйдәләрен һәм принципларын яктырткан беренче зур күләмле хезмәт булды.

Латыйф Җәләй киңкырлы һәм теоретик әзерлекле галим буларак, үзе яшәгән чордан алга китеп, татар тел гыйлеменең үсеш перспективаларын, яңа сукмакларын билгели. «Социалистик Татарстан» гәзитендә 1956 елда басылган «Татар тел белеме алдындагы бурычлар» исемле мәкаләсендә Л.Җәләй татар

теленең тулы аңлатмалы сүзлеген төзү, әдәби телне стилистик яктан эшкәртү, диалектологик атлас һәм тулы диалектологик сүзлек төзү һ.б. проблемаларны тиз арада тормышка ашырырга кирәк дигән фикер үткәрә. Бу бик вакытлы әйтелгән сүз иде, бүгенге көндә аны Латыйф аганың шәкертләре һәм хезмәттәшләре уңышлы рәвештә тормышка ашыралар [1:6].

Шулай итеп, Латыйф Җәләлетдин улы Җәләлетдинов (Латыйф Җәләй) хезмәтләре татар лингвистика фәненең диалектология, әдәби тел тарихы, тарихи грамматика, лингвоэтнотарих һәм сөйләм культурасы кебек мөстәкыйль тармаклары формалашуда нигез булдылар.

**Әдәбият**

1. *Зәкиев М.З.* Латыйф Җәләй һәм милләт язмышы мәсьәләләре // Актуальные вопросы татарского языкознания. Вып. 4. Казань, 2005. 3-18 б.
2. Залялетдинов Латыф Залялетдинович // Казанская лингвистическая школа: Книга первая: Казанская тюркская лингвистическая школа. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. С. 64-68.
3. *Баязитова Ф.С.* Туган тел һәм Латыйф Җәләйнең олы мирасы // Актуальные вопросы татарского языкознания. Вып. 4. Казань, 2005. 18-24 б.